DOI: 10.26907/2311-2042-2025-24-1-49-58

# A LOOK AT N. ISANBET'S WORKS IN THE FIELD OF TATAR FOLKLORE

**Liliia Khatipovna Mukhametzianova,**
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art,
Tatarstan Academy of Sciences,
12 K. Marks Str., Kazan, 420111, Russian Federation,
lilmuhat@mail.ru.

Tatar folklore is a spiritual gem that has been created by the people over the centuries and passed down from generation to generation. Folkloristics is a rich, complex, deep and important area of Tatar science, which, being of exceptional significance, makes up the spiritual foundation of our time. There are not many talented Tatar scholars who devoted their lives to the study of the Tatar people's unique heritage, revealing the exciting scientific secrets in this area. One of the rare personalities, who made significant contributions to the popularization of the Tatars' heritage and to the preservation of national folklore monuments, is the Tatar writer, folklorist and scholar Nakie Isanbet (Nakie Sirazievich Isanbet). Our article describes the work of this outstanding figure who found folklore works from the depths of centuries, processed them according to the current requirements of science and, having determined their value, passed them to future generations. From the perspective of national and cultural values, the article gives a scientific assessment of N. Isanbet's work in the field of Tatar folklore and folklorism, highlights the significance of the provided materials, which greatly contributed to the study of various Tatar folk art genres, and defines the prospects on conducting further research in this direction.

**Key words**: Tatar folk art, folklore, personality of Nakie Isanbet

**For citation:** Mukhametzianova, L. A look at N. Isanbet's works in the field of Tatar folklore // Tatarica. 2025. № 1 (24). pp. 49–58. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-49-58

## Introduction

All his life, the gems of folk art were the focus of Nakie Isanbet's attention, Nakie Sirazetdinovich Isanbet who was the Aksakal of Tatar literature, the famous playwright, poet, prose writer and scientist-folklorist. Naki Isanbet belonged to those rare personalities who were gifted since birth. Like the Tatar saying goes, "a talented child even at the age of six will say that he is the head, while a failed one will say that he is too young even at the age of sixty", Nakie was born a leader who was talented. During his studies, in the "Khusania" and the "Galia" Madrasahs in Ufa in 1910–1917, then in the "Mukhammadia" Madrasah in Kazan, that is, since his students' years, he showed interest in the gems of oral folk art and believed that it was necessary to collect and preserve them.

N. Isanbet collected, scientifically studied, systematized and published the Tatar people's oral folk legacy. He prepared and published a three-volume book "Tatar Khalyk Makallare" ("Tatar Folk Proverbs") (1959, 1963, 1967, 2010) containing about forty thousand units, and the phraseological dictionary (1989, 1990) consisting of fifty thousand units, the voluminous edition of "Tatar khalyk tabishmaklary" ("Tatar Folk Riddles") (1970) and a collection of children's folklore (1970, 1973) – these are all fundamental works created in the course of studying Tatar folklore (see: [1, pp. 171–190]). This is a well-known fact that for his three-volume "Tatar khalyk makkallare" ("Tatar Folk Proverbs"), the scholar got the award named after G. Tukay in 1968. N. Isanbet's research into small epic folk genres conducted by him from his young age, and oral creative art in general is evaluated today as a truely titanic work. The mentioned collections are voluminous works that open the doors to the world of Tatar folklore. Each of them is important not only for a connoisseur of folklore, but also for all our people because of their completeness, detailed introductory articles by Naki aga, scientific and historical explanations and a perfect scientific apparatus, since these works were found in the depths of time and returned back, the gems returned to the people. At the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan,

when writing research works devoted to epics and dastans, folklorists often turn to the folklore heritage left by Naki Isanbet.

**Materials and research methods**

This article reviews Naki Isanbet's work in the field of Tatar oral folk art, exploring and evaluating his most fundamental works performed in two main areas of folklore: collection and analysis of the collected material. Our study is based on N. Isanbet's works in the field of Tatar folklore: his published books, archival documents and literary works, reflecting folklore traditions. The biographical, descriptive and axiological methods were used as the main research methods. We used the biographical and descriptive methods to explore N. Isanbet's work on Tatar folklore, tracing the sparks of folk art in the works of the writer; with the help of the axiological approach, we attempted to give a contemporary objective assessment of Naki Isanbet's activities as a folklorist in the context of national and cultural values.

**Discussion**

The sources, mentioning Tatar chichans, are rare, since the tradition of chichans' (a bard in Turkic Culture (chachan, sasan, aqyn)) dastan recitals to the sound of dombra goes back to a sedentary lifestyle, it existed before other Turks, for example, Kazakhs, Nogais, Sakha and Bashkirs had it; therefore, Tatar chichans' work did not develop in a traditional way. However, if in the past times the Tatars had not had chichans and they had had no habit of humming epics and dastans, today there would be no such beautiful folk dastans as "Kuzy Kurpach Belan Bayan Sylu" ("Kuza Kurpach and Bayan the Beauty"), "Alpamysh" ("Alpamysh"), "Tulak" ("Tulak"), "Idegay" ("Idegay") and "Chura Batyr" ("Chura Batyr"), we would not have epic songs based on dastans whose roots are in oral folk art. It was Naki Isanbet – one of the rare thinkers of his time, who, when describing a person who used to be a Tatar chichan, subtly clarified the duties and other characteristic features of the Tatar folklore artist, preserving till our days such common-Turkic images as Red Chichan, Subra Zhyrau and Jamukai Zhyrau. He talked to the chichans of his time and collected their works. In the early 1920s, in the village of Saitovo in Bashkortostan, he recorded ancient songs sung by the chichan named Fayzulla, and came close to the Blind Farrah (Farrah Davletshin) from the former Bir District of Bashkortostan; he described their meetings in "Suz Tabuchy Sukyr Farrah angamalare" ("Talks with Farrah, a Master of the Word"), "Farrah zhyrlary turynda" ("On Farrah's Songs") [2, pp. 487–489]. Therefore, Naki aga could be called an expert in the epic. He described in detail the similarities of the Tatar folk epics and dastans with the genres performed by chichans, such as the saryn, tulgau and epic song. By resolution of the Central Committee of the All-Union Communist Party of Bolsheviks of August 9, 1944, the scientific study of the Tatar people's dastans was officially prohibited. N. Isanbet was a brave man who could not come to terms with this injustice. Nakie aga's interest in the Turkic epic was of great importance for that time, it was a reminder that the Tatars had excellent epic works and dastans. A highly appreciated achievement was the publication of "Idegay" in his own poetic interpretation in 1940 [3].

Indeed, from the point of view of N. Isanbet's work on folklore, the dastan "Idegay" presents a separate extensive research area. The "Idegay" is a common heritage for many Turks, its various versions and interpretations exist among other peoples. But no other peoples, who formed part of the Golden Horde, reached such high poetic perfection of the epic as the Tatar "Idegay"! Nakie aga played a huge role in the preservation of this gem in Tatar. The poetic text of the "Idegay", which is called the Isanbetan version of the "Idegay" in the academic language, was assembled from well-known versions and interpretations and was made with exceptional professionalism. In the $20^{th}$ century, Isanbet breathed a new life into the "Idegay", the epic that has been sung since the $15^{th}$ century. It is noteworthy that nowadays both the academic societies and common people, including schoolchildren, know only the version of Nakie aga's "Idegay", the same applies to artists and directors who take up the theme of the "Idegay" as the subject of their works. Recently, the general public has learned the Isanbetan version of the "Idegay" and its translation, although the Tatars have many long and short variants of the dastan. The folklore work, if it is not recorded, if it is not properly processed and published on time, is doomed to oblivion and loss over time. But the "Idegay" is undoubtedly a monument that has had a happy fate due to the efforts of such a prominent intellectual as N. Isanbet, who was the owner of a rare and original talent, able to leave these luxurious gift to his people. It happened so because it was a collective work, even though it was a piece

of folklore; however, the principle of individuation always played an important role in creating an epic-dastan, brought to perfection by the hand of an individual master of the pen. This interpretation can be compared with the "Ramayana" by Valmiki, the "Iliad", "Odyssey" by Homer and the famous "Kalevala" by Elias Lenrot. By the middle of the 20th century, Isanbet, having collected different folk versions, had woven them with one thread, masterfully observing the canons of folklore, and had recreated the Tatar "Idegay" in its poetic version. This collective version of the "Idegay", painstakingly created by N. Isanbet, is a truly great work, a crown of folklore works that have absorbed the idea of statehood in the modern Tatar world.

Folk art had a great influence on N. Isanbet as a writer and playwright. His plays "Zhiran chichan belan Karachachsylu" ("The Red-Haired Chichan and the Black-Haired Beauty"), "Tulak" ("Tulyak"), "Khuzha Nasretdin" ("Khoja Nasretdin"), the "Idegay" and other works were imbued with folk color. In his article "My Formation as a Writer and the Study of Folk Art", N. Isanbet wrote: "For fifty years, along with the writing various poems, dramas and other works, I have never given up the collection and study of folk art. <...> First of all, I really love oral folk art, I really appreciate it" [2, pp. 109–113]. (This is the article of 1960, in addition, comes his article of 1928 "On Farrah's Songs" [2, pp. 487–489] and other valuable materials collected and published in one book by Mileusha Khabutdinova and the "Zhyen" Foundation in 2021 [2]). In these works, for the first time in Tatar folklore, we see N. Isanbet's attempt to raise the issue of collecting folklore genres directly from people, and providing the scientific basis. That is, starting from his own experience, he put on the agenda the importance of creating a folklore expedition. He revealed the features characterizing the process of collecting proverbs, sayings, riddles, folk songs, fairy tales and bayts and compiled a kind of instruction for folklore collectors. The theory of folklore cannot be combined with its practical aspect, that is, with the collection of material directly from people, in this sense N. Isanbet was a real scientist-folklorist who was well aware of the specificity of this work and could explain it. (*See*: [4], [5], [6], etc.)

In recent years, the concept of the folk song, that is, the song of everyday life, has appeared among folklore genres. There is no certain order, or strictly established requirements for this group of works in science. The category of "the folk song" includes the works that have successfully withstood the test of popularity and have been relatively long preserved in folk memory, they have been transmitted from mouth to mouth and sung over generations, although having certain variables. There are few such examples, but they exist. The melody of folk songs may belong to the author, while the lyrics may belong to the people, or, conversely, the melody may belong to the people and the lyrics may belong to a particular person. For example, we can consider the songs that have sunk into the soul of every Tatar: the songs sung to the folk melody – "Tugan Tel" ("Mother Tongue"), "Allyuki" (Lullaby) (lyrics by Tukay), "Fazyl Chishmase" ("Fazyl's Spring") (lyrics by Sibgat Khakim), "Kerdem Carurmannarga" ("I Went into Dense Forests") (lyrics by Gulshat Zainasheva), "Shakhta" ("The Mine") (lyrics by Shaihu Mannur), "Umyrzaya" ("A Snowdrop") (lyrics by Akhmet Fayzi), or conversely, the composer wrote the melody based on folk lyrics "Avyl Koe" ("The Village Melody") (Rais Safiullin), "Bagyrkaem, Onytmamyn" ("My Dear, I Will Not Forget") (music by Rim Khasanov) and others. There are such everyday songs whose lyrics and melody are the work of an outstanding poet and a talented composer, they are very warmly accepted by the people, becoming our folklore. They have new versions that both professional singers and ordinary people sing with pleasure, and the audience enjoy listening to. For example, the song by Robert Minnullin and Sarah Sadykova "Ankay bezne Sonnan alyp kaitkan" ("Our Mother Brought Us from Syun"), and Sarah Sadykova's song "Jidegan chishma" ("The Spring Jidegan") with Gumer Bashirov and "Kazan Kichlare" with Kh. Tufan.

Our article explores the concept of "the folk song" in folklorism in more detail due to the desire to express our opinion about Naki Isanbet's works, which also belong to this category. For, the poem "Urakchy Kyz" (The Reaper Girl), written back in the 1920s, and the melody to this poem were written simultaneously. Today, the melody of this song is differently assigned to Dzhaudat Fayzi, or is believed to be a folk melody, other assumptions are suggested. The answer to the question of who wrote the song's melody was clarified by Naki aga himself: "Abdullah Shamukov," he said, "claims that the author of the musical comedy "Bashmagim" ("My Shoe") Khabibulla Ibrahimov was the author of the melody. But whether "Urakchy Kyz" was written by him, I do not know for sure" [7, p. 3]. The fact that this wonderful

song, based on such a story, is called the folk song of N. Isanbet today is undoubtedly due to the fact that it is the work that has won folk love. Its attribution to the category of folk songs increases the authority of both the work itself and its author. The same thing can be said about the folk song “Ilkaem” (“My Country”), based on Naki Isanbet’s lyrics, and the song “Sin sazynny uinadyn” (“You Played Your Saz”), attributed both to Ilham Shakirov and to folk songs. The songs “Garmunchy eget” (“The Young Accordionist”), “Bormaly Su” (“The Winding River”) can be considered both popular and folk works. The fact that these songs, whose author was N. Isanbet, have become folklore works, on the one hand, shows the continuous process of literature and folklore interaction, on the other, indicates how close the author was to his people. The people have never been indifferent to their national-ethnic history, life, mentality, psychology and, of course, the wealth of their national language. This means that N. Isanbet’s verses, which have become people’s songs, are creative art that meets high requirements.

The funds of the Center for the Writing Heritage at the G. Ibrahimov Institute of Language, Language and Art, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, store a number of documents related to the “Idegey” written by N. Isanbet [8]; [9], [10], [11] and serious research works devoted to the activities of the scholar in folklore [1], [12]; [13, 160–173]; [14]; [15], [16], etc.; however, there are very few of these studies, so doctoral dissertations and scientific monographs could contribute significantly to the existing body of knowledge by studying each document, collecting bit by bit Naki aga’s achievements in folklore art, history, literature and Tatar studies – in every area. Of special interest is his archive, which is hitherto known to the general public only thanks to M. M. Khabutdinova’s work, describing the documents that have not been introduced into the scientific circulation, especially those related to the field of folklore, they are highly anticipated by both the scientific society and the population in general [17], [18].

N. Isanbet talked to the scholars of our institute in connection with the events related to the creation of the “Idegey” dastan version. The researchers at the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, developing a fundamental scientific trend in Tatars Studies, maintain exceptionally positive scientific views on Naki Isanbet’s work, distinguishing him among different generations of scholars-folklorists. The folklorists of the senior generation, who worked in the Department of Folk Art, recalled Naki aga with sincere admiration: “He was a very big scholar”, “A wonderful person”, “Talented, rare person among the Tatars”, “A real scholar who achieved great success”, “A folklorist with a keen sense of language.”

## Results

Summing up, we can say that it was Tatar folklore that raised Naki aga who deeply understood the value of this inexhaustible folk treasure, and the writer gave it back to his people. The greatness and nobility of Naki Isanbet’s personality is due, first of all, to his work, associated with the area closest to his people – their folklore. We must read, know and use Naki aga’s notes on folklore works and Tatar culture as a whole. The name of this person, all his life were devoted to folk art, and we hear them sound in the Tatar world often and proudly today.

**References**


1. Khanzafarov, N. (1982). *Naki Isanbet dramaturgiyase* [Naki Isanbet’s Dramaturgy]. 192 p. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)
2. *Nakie Isanbet: fanni-populyar zhyentyk* (2021) [Naki Isanbet: Popular Science Collection]. Compl. M. M. Khabutdinova. 736 p. Kazan, Zhyen. (In Tatar)
3. Isanbet, N. (1940). *Tatar khalyk eposy “Idegey” dastanynyn 500 ellygy* [500th Anniversary of the Tatar Folk Epic Dastan “Idegey”]. Sovet adabiyaty. No. 11, pp. 39–92. No. 12, pp. 34–98. (In Tatar)
4. Urmancheev, F. (1967). *Isanbet ham tatar khalyk izhaty* [Isanbet and Tatar Folk Art]. Pp. 37–73. Adip ham galim. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)
5. Khabutdinova, M. M. (2024). *Naki Isanbet and Tatar Folklore.* Tatarica. No. 2 (23), pp. 148–161. (In English)
6. Khabutdinova, M. M., Khabibullin, F. A. (2021). *Naki Isanbet chichanlek sangate turynda* [Nakie Isanbet on Chichan Art]. Tatarica. No. 2 (17), pp. 119–140. (In English)
7. Isanbet, N. (1922). *Urakchy kyz (poem)* [The Reaper Girl]. Kyzyl Sharyk yashlare. 3 p. Kazan. (In Tatar)
8. *Materialy ob “Idegey”* [Materials on “Idegey”]. Mashinopis na tatarskom yazyke. TSPN im. G. Ibragimova AN RT. F. 52, op. 1., ed.khr. 198. Inv. 498. (In Tatar)
9. *Poyasneniya k narodnomu ehposu “Idegey”* [Explanations to the Folk Epos “Idegey”]. Na 27 listakh. 26 sentyabrya 1941 g. TSPN im. G. Ibragimova AN RT. F. 52, op. 1., ed.khr. 210. (In Russian)
10. *Ob ehpose “Idegei”. Vosstanie idegeistov i sotsial'no-istoricheeskie prichiny, sposobstvovavshie vozniknoveniyu ehtogo ehposa* [On the Epic “Idegey”.

The Uprising of Idegeists and the Socio-Historical Reasons that Contributed to the Emergence of this Epic]. Mashinopis na 38 listakh. TSPN im. G. Ibragimova AN RT. Fond 52, op. 1., ed.khr. 192. (In Russian)

11. *Materialy ob "Idegey". 1940.* [Materials on "Idegey". 1940]. TSPN im. G. Ibragimova AN RT. F. 52. Op. 1. ed.khr. 201. (In Russian)

12. Nadirov, I. N. (1999). *Narodnyi ehpos "Idegey"* [Folk Epos "Idegey"]. Srednevekovaya tatarskaya literatura (VIII–XVIII vv. ). Pp. 103–106. Kazan, Fen. (In Russian)

13. Fatikh Urmancheev (2023). *Tatarskii narodnyi ehpos* [Tatar Folk Epos]. 384 p. Kazan. (In Russian)

14. Khabutdinova, M. M. (2023). *Vklad Naki Isanbeta v izuchenie Zolotoi Ordy* [The Contribution of Nakie Isanbet to the Study of the Golden Horde]. Zolotoordynskoe obozrenie. T. 11, No. 1, pp. 181–201. DOI: 10.22378/2313-6197.2023-11-1.181-201 EDN: NZKGGK. (In Russian)

15. Zamaletdinov, R. R, Khabutdinova, M. M. (2023*). The Creative History of Naki Isanbet's Comedy "Red-Haired Chichyan and Black-Haired Beauty".* Zolotoordynskoe Obozrenie. P. 934–956. Vol.11, Is.4. DOI: 10.22378/2313 6197.2023-11-4.934-956. (In English)

16. Khabutdinova, M. M. (2024). *The History of the Creation and Promotion of the First Consolidated Text of the Bashkir Folk Epic "Idukai and Muradim".* Zolotoordynskoe obozrenie=Golden Horde Review. vol. 12, no. 4, pp. 943–969. https://doi.org/ 10.22378/2313-6197.2024-12-4.943-969. (In English)

17. Isanbet, N. (2023). *Kazan artyna berenche sayakhatem: "Ory akkan"* [My First Journey beyond Kazan: "Ura Flooded"]. Tatarica. No. 2 (21), pp. 76–100. (In Tatar)

18. Isanbet, N. (2023). *"Kongyr boga" koe: tarikhi tamyrlary ham poetikasy torki khalyklar madaniyate kontekstynda* [The Song "Kongyr Boga": Its Historical Roots and Poetics in the Context of the Turkic Peoples' Culture]. Tatarica. No. 1 (20), pp. 32–43. (In Tatar)

# Н. ИСӘНБӘТНЕҢ ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ БЕР КАРАШ

**Лилия Хатип кызы Мөхәммәтҗанова,**
Татарстан Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты,
Россия, 420111, Казан ш., Карл Маркс ур., 12 нче йорт,
lilmuhat@mail.ru.

Татар фольклоры – халкыбыз тарафыннан гасырлар дәвамында иҗат ителә килгән, буыннан-буынга тапшырылган кыйммәтле рухи хәзинә. Фольклористика – татар фәненең бай, катлаулы, тирән һәм тәэсирле, бүгенгенең рухи тамырларын тәшкил иткән гаҗәеп мәгънәле өлкәсе. Гомере буе халкыбызның шушы гаять үзенчәлекле мирасын барлаучы, башкаларга бу өлкәнең мавыктыргыч серләрен ачучы көчле фикерле татар галимнәре әллә ни күп түгел. Халкыбыз мирасының тиешле югарылыкта халыкка җиткерелүенә, башка халыклар янәшәсендә горурланырлык ядкярләребезнең бүгенге көнгә килеп ирешүенә зур өлеш керткән сирәк шәхесләрнең берсе – татар әдибе, фольклорчы галим Нәкый Исәнбәт (Нәкый Сираҗетдин улы Исәнбәт). Бу мәкаләдә автор әлеге күренекле шәхеснең гасырлар тирәнлегеннән фольклор әсәрләрен табып алып, безнең чорга якынайту һәм, аларның кыйммәтен билгеләп, киләчәк буыннарга тапшыру белән шөгыльләнүе хакында сүз алып бара, милли-мәдәни кыйммәтләр югарылыгыннан торып, эрудит-галим Н. Исәнбәтнең татар фольклоры юнәлешендәге зур эшчәнлегенә фәнни бәя бирә, татар фольклорының төрле жанрларына карата ул калдырган материалларның әһәмиятен ассызыклый, бу өлкәдә алып барылырга тиешле эшләрнең потенциалы дәрәҗәсен билгели.

**Төп төшенчәләр:** татар халык иҗаты, фольклористика фәне, татар шәхесе Нәкый Исәнбәт

**Сылтама өчен:** Мөхәммәтҗанова Л.Х. Н. Исәнбәтнең татар фольклоры өлкәсендәге эшчәнлегенә бер караш // Tatarica. 2025. № 1 (24). 49–58 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-49-58

## Кереш

Татар әдәбиятының аксакалы, танылган драматург, шагыйрь, прозаик, фольклорчы галим Нәкый Исәнбәтнең (Нәкый Сираҗетдин улы Исәнбәт) зур шәхескә әверелүе аның халык иҗаты җәүһәрләренә гомере буена аерым

әһәмият бирә килүе шартларында башкарылган. Нәкый Исәнбәт – тумышыннан ук белеп туган сирәк затларның берсе. «Булган бала алтыда да мин баш дияр, булмаганы алтмышта да мин яшь дияр» дигән гыйбарәдәге кебек, Нәкый ага – баш булып, булдыклы булып, белеп туган даһи. 1910–1917 елларда Уфадагы «Хәсәния», «Галия» аннан соң Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә укыганда, ягъни япь-яшь шәкерт вакытыннан ук халык җәүһәрләренә игътибар итеп, аларны туплый баруны кирәк дип тапкан кешене башкача бәяләп булмый.

Н. Исәнбәт татар халкының тел, авыз иҗаты хәзинәләрен, сүз сәнгатен җыю, барлау, гыйльми өйрәнү һәм аларны системага салып, бастырып чыгару эше белән шөгыльләнгән. Аның тарафыннан әзерләнгән һәм кырык меңгә якын берәмлекне үз эченә алган өч томлык «Татар халык мәкальләре» (1959, 1963, 1967, 2010), илле мең берәмлектән торган фразеологик сүзлек (1989, 1990), зур күләмле «Татар халык табышмаклары» (1970) һәм балалар фольклоры җыентыклары (1970, 1973) – болар татар фольклорын өйрәнү юлында ирешелгән фундаменталь хезмәтләр (*Кар.:* [1, 171–190]). Өч томлык «Татар халык мәкальләре» китабы өчен әдип 1968 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булганлыгын барыбыз да белә. Халыкның кече эпик жанрларына, сүз сәнгатенә Н. Исәнбәтнең яшь вакытыннан ук бирә килгән игътибары бүгенге көндә чын мәгънәсендә титаник хезмәтләр буларак бәяләнә. Атап кителгән әлеге җыентыклар, зур-зур томнар – татар фольклор дөньясын ача торган хезмәтләр. Боларның һәркайсы үзләренең тулылыгы, ул томнарга Нәкый ага тарафыннан язылган саллы-саллы кереш мәкаләләре, авторның эпик жанрларга биргән гыйльми-тарихи аңлатмалары, гомумән, камил фәнни аппараты белән – фольклор белгече өчен генә түгел, милләтебез өчен кадерле, үз вакытында табылган, халыкка кире кайтарылган якутлар. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эпос-дастаннарга багышланган фәнни хезмәтләр язу барышында фольклорчы галимнәр Нәкый Исәнбәт калдырган фольклор хәзинәләренә еш мөрәҗәгать итә.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Әлеге мәкаләдә Нәкый Исәнбәтнең татар халык иҗаты өлкәсендә эшчәнлегенә күзәтү ясала, аның фольклористиканың ике зур юнәлеше булган җыю-туплау һәм өйрәнү-тикшеренү өлкәләрендә башкарган иң төп эшләре барлана һәм бәяләнә. Тикшеренү материаллары корпусын Н. Исәнбәтнең татар фольклоры өлкәсендә эшләп калдырган хезмәтләре – басылып чыккан китаплары, архив документлары һәм фольклор традицияләре чагылыш тапкан әдәби әсәрләре тәэзи. Тикшерүнең төп методлары буларак, биографик, тасвирлама һәм аксиологик методлар кулланылды. Биографик метод һәм тасвирлама методлар ярдәмендә автор Н. Исәнбәтнең татар фольклорын үстерү эшчәнлеген барлый, әдип әсәрләрендә халык иҗаты чаткылары үстерелешен күзәтә; аксиологик якын килү ярдәмендә Нәкый Исәнбәтнең фольклорчы буларак эшчәнлегенә милли-мәдәни кыйммәтләр яссылыгында заманча объектив бәя бирергә омтыла.

## Фикер алышу

Татар чичәннәре турында сүзне бик сирәк чыганактан табарга мөмкин, чөнки сүз остасы чичәннәр тарафыннан халык алдында думбра чиртеп, дастан әйтү традициясе утрак тормышка иртә күчкән, шәһәр культурасы алга киткән, күңелен китап, язма сүз яулаган укымышлы татарларда башка кайбер төркиләргә, әйтик, казакъ, нугай, саха, башкортларга караганда алдарак сүрелгән, шуңа бәйле татар чичәннәре иҗаты да гадәти юл белән түгел, китаби-язма рәвешкә күчеп, үсеш алган. Әмма әгәр үткән чорларда татарда чичәннәр һәм аның эпос-дастанны көйләп әйтү гадәте булмаган булса, бүген халыкның «Кузы Көрпәч белән Баян сылу», «Алпамыш», «Түләк», «Идегәй», «Чура батыр» кебек гүзәл дастаннары, әле дә очрап тора торган дастаннан эпик җыр башкарулар берсе дә булмас иде, боларның барысының тамырлары – халыкның телдән әйтеп башкара килгән сүз сәнгатендә. Шуннан чыгып, үз вакытында татар чичәненең кем булуын тасвирлап, ул башкарган вазифаларны һәм татар фольклорына хас башка хасиятләрне нечкә аңлатып язган, Җирән чичән, Субра җырау, Җамукай чичән кебек гомумтөрки җырау образларын безнең көннәргә китереп җиткергән, үз чоры чичәннәре белән аралашкан, алардан иҗат түле җыйган сирәк фикер ияләренең берсе – нәкъ менә Нәкый Исәнбәт. XX йөзнең 20 нче еллары башында ук ул Башкортстанның Сәет авылында Фәйзулла исемле чичәннән борынгы

җырлар яздырып ала, шулай ук Башкортстанның элеккеге Бөре өязеннән сукыр Фәррах (Фәррах Дәүләтшин) белән якыннан аралаша, аның хакында «Сүз табучы Фәррах», «Фәррах җырлары турында» дип язып та чыга [2, 487–489 б.]. Шуңа да чичән башкаруындагы сарын, тулгау, эпик җыр һ.б.ның татар халык эпос-дастаннарына хас сыйфатлар булуы, аларның үзенчәлекләре хакында тәфсилләп язып калдырган Нәкый аганы эпос белгече дип атау дөрес. ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елгы 9 август карары белән татар халкындагы дастани мирасны фәнни өйрәнү рәсми тыелган заманда яшәгән Н. Исәнбәт – бу гаделсезлек белән килешә алмаган кыю зат. Төрки эпоска карата Нәкый аганың игътибары, татарда гүзәл эпос-дастаннар бар дип искәртүе заманы өчен зур әһәмияткә ия. Халык иҗаты кануннарын үтә бер зәвык белән тоеп, үзе шигъри эшкәртеп чыккан «Идегәй»не [3] 1940 елда дөньяга чыгара алуы гына да – югары бәяләнерлек казаныш.

Чыннан да, Н. Исәнбәтнең фольклордагы эшчәнлеге ягыннан «Идегәй» дастаны – аерым өлкә. «Идегәй» – күп төркиләр өчен уртак мирас, аның төрле версия һәм вариантлары татарлардан тыш, кайбер башка халыкларда бар. Әмма Алтын Урда составына кергән «Идегәй»ле бүтән бер генә халыкта да татар телле «Идегәй» кебек югары шигъри камиллеккә җиткерелгәне юк! Татарда аның булуында Нәкый аганың роле бик зур. «Идегәй»нең фәнни телдә Н. Исәнбәт варианты дип йөртелә торган шигъри тексты, билгеле версия-вариантлардан җыйнап, гаҗәеп бер профессиональ осталык белән эшләнгән. Исәнбәт «Идегәй»гә, XV гасырдан ук җырлана-әйтелә килгән эпоска XX гасырда яңа сулыш өргән. Игътибар итсәк, фәнни даирәдән кала гади халыкка, шул исәптән мәктәп укучыларына, бүген «Идегәй» Нәкый ага варианты аша гына таныш та, «Идегәй» темасына алынган рәссамнар, режиссёрлар өчен дә бу шулай. Соңгы чорда киң җәмәгатьчелеккә «Идегәй»не нәкъ менә Исәнбәт варианты һәм аның тәрҗемәсе таныта, гәрчә дастанның эреле-ваклы вариантлары татарда шактый булса да. Фольклор әсәренә, әгәр вакытында язып алынмаса, эшкәртелеп, халыкка җиткерелмәсә, азмы-күпме вакыт үтүгә онытылу, югалу хас. Ә менә Н. Исәнбәт кебек күренекле зыялы игътибарына юлыккан «Идегәе»без ул яктан гаять дәрәҗәдә бәхетле язмышка ия ядкяр, сирәк һәм үзенчәлекле талант иясенең генә үз халкына шушындый затлы истәлек калдыра алуы бәхәссез. Ни өчен дисәк, коллектив иҗат җимеше, фольклор әсәре дисәк тә, эпос-дастаннарны иҗат итүдә һәрвакыт индивидуаль башлангыч зур роль уйнаган, аерым бер каләм остасы кулы белән камиллек дәрәҗәсенә җиткерелгән мондый вариантны Вальмикиның «Рамаяна»сы, Гомерның «Илиада»сы, «Одиссея»сы белән, атаклы «Калевала»ның Элиас Лёнротка нисбәт ителүе белән чагыштырып булыр иде. XX гасыр уртасына җиткәндә, Исәнбәт тә, халык вариантларын җыйнап, бер җепкә тезеп, фольклор кануннарын үтә бер осталык белән саклап, шигъри вариантта татар «Идегәе»н янә торгызган. «Идегәй»нең Н. Исәнбәт күп көч салып булдырылган әлеге җыйнама варианты – дәүләтчелек идеясен бүгенге татар дөньясына китереп җиткергән чын мәгънәсендә бөек әсәр, фольклор әсәрләренең таҗы.

Язучы, драматург буларак та халык иҗаты Н. Исәнбәткә зур йогынты ясаган. «Җирән чичән белән Карачәч сылу», «Түләк», «Хуҗа Насретдин», «Идегәй» пьесалары, башка әсәрләре халыкчан затлылык белән сугарылган булу шуны раслый. Н. Исәнбәт үзенең «Минем язучы булуым һәм халык иҗатын өйрәнүем» дигән мәкаләсендә болай дип язган: «Илле ел буена төрле шигырьләр, драмалар һ.б. әсәрләр язуым белән бергә, бу халык иҗатын җыю һәм өйрәнүне бервакытта да ташламадым. <...> Мин халык авыз иҗатын иң элек үзен бик яратам, аңа бик зур бәя бирәм» [2, 109–113 б.]. (1960 елгы бу язманы, моннан тыш, аның 1928 елгы «Фәррах җырлары турында» мәкаләсен [2, 487–489 б.] һ.б. кыйммәтле материалларны Миләүшә Хәбетдинова һәм «Җыен» фонды 2021 елда бер китапка җыйнап бастырып та чыгарды [2]). Әлеге язмаларда Н. Исәнбәтнең татар фольклористикасында беренчеләрдән булып халыктан фольклор жанрларын ни рәвешле җыярга кирәклек мәсьәләсен фәнни нигезгә куярга омтылышын күрәбез. Ягъни ул, үз тәҗрибәсеннән этәрелеп, фольклор экспедициясе нигезләмәсен булдыруның әһәмиятен көн кадагына бастыра, мәкаль-әйтем, табышмак, халык җырлары, әкиятләр, бәетләр һ.б. шундый үрнәкләрне туплауның серен-хикмәтен ачыклый, фольклор җыючы өчен үзенә күрә инструкция төзи. Фольклор теориясен аның гамәли ягы, ягъни халыктан материал җыйнау белән бергә алып бармый булмый, бу җәһәттән дә Н. Исәнбәт – шушы хакыйкатьне тирән аңлап һәм аңлатып эш

иткән чын фольклорчы-галим. (*Кар*.: [4], [5], [6] һ. б.)

Фольклор жанрлары арасында соңгы елларда халыклашкан җыр, ягъни көндәлек масса җырлары дигән төшенчә барлыкка килде. Бу төркем әсәрләргә карата фәндә аерым бер тәртип, ныклап урнашкан таләпләр юк. «Халыклашкан җыр» категориясенә популярлык сынавын гаять уңышлы үтеп, халык күңелендә чагыштырмача озакка сакланып калган, телдән-телгә күчеп, буыннан-буынга җырлана килгән, вариантлыкка ия әсәрләр керә. Мондый хокукны яулаган үрнәкләр сирәк, әмма алар бар. Халыклашкан җырларның көе авторныкы булып, сүзләре халыкныкы, яисә, киресенчә, көе халыкныкы саналып, сүзләре мәгълүм кешенеке булырга мөмкин. Мәсәлән, халык көенә «Туган тел», «Әллүки» (Тукай сүзләре), «Фазыл чишмәсе» (Сибгат Хәким сүзләре), «Кердем карурманнарга» (Гөлшат Зәйнашева сүзләре), «Шахта» (Шәйхи Маннур сүзләре), «Умырзая» (Әхмәт Фәйзи сүзләре) яисә, киресенчә, халык сүзләренә композитор көй язган «Авыл көе» (Рәис Сафиуллин), «Бәгырькәем, онытмамын» (Рим Хәсәнов көе) һ.б. – һәр татарның күңелен биләгән җырлар. Хәтта сүзләре дә, көе дә атаклы шагыйрь белән талантлы композитор иҗаты булса да, халык тарафыннан гаять җылы кабул ителгән, күз алдында чын-чынлап фольклорлашкан, яңадан-яңа вариантлары таралыш алган, профессиональ җырчылар да, гади халык та яратып җырлый, ә аудитория кинәнеп тыңлый торган көндәлек җырлар бар. Әйтик, Роберт Миңнуллин белән Сара Садыйкованың «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан» җыры, яисә Сара Садыйкованың Гомәр Бәширов белән «Җидегән чишмә», Х. Туфан белән «Казан кичләре» моңа мисал була ала.

Мәкаләбездә фольклористикада «халыклашкан җыр» дигән төшенчәгә тәфсилләбрәк тукталуның сәбәбе – Нәкый Исәнбәтнең дә шушы категориягә керә торган әсәрләре хакында фикер җиткерергә теләү. XX гасырның 20 нче елларында ук иҗат ителгән «Уракчы кыз» шигыренә үз чорында көй языла. Бүгенге көндә бу җырның көе Җәүдәт Фәйзи көе, халык көе һ.б. дип төрлечә тамгалана. Җырның көен кем язганлык мәсьәләсенә Нәкый ага үзе болай дип ачыклык кертә: «Габдулла Шамуков, – ди ул, – бу көйне «Башмагым» музыка-комедия авторы Хәбибулла Ибраһимов чыгарды дип раслый. Әмма «Уракчы кыз» аның тарафыннан язылдымы, анысын ачык кына белмим» [7, 3 б.]. Менә шундый тарихы булган бу гаҗәеп матур җырны бүген, Н. Исәнбәтнең халыклашкан җыры дип атау, шиксез, җырның халык мәхәббәтен яулаган әсәр булуыннан килә. Халыклашкан җыр дигән төркемгә кертеп карау әсәрнең дә, авторның да мәртәбәсен арттыра. Сүзләре Нәкый Исәнбәтнеке, көе – халыкныкы булган «Илкәем» җыры, көе Илһам Шакировка йә халыкка нисбәт ителә торган «Син сазыңны уйнадың» да шундый ук дәрәҗәгә ия ядкярләр. «Гармунчы егет», «Бормалы су»ны да популяр гына түгел, халыклашкан әсәрләр рәтендә карарга мөмкин. Авторы Н. Исәнбәт булган әлеге җырларның фольклор әсәре булып әверелүе, бер яктан, әдәбият белән фольклорның туктаусыз алмашу процессын күрсәтсә, икенче яктан, авторның халыкка үтә якынлыгын раслый. Халык үз милли-этник тарихына, яшәешенә, менталитетына, психологиясенә һәм, әлбәттә, милли тел байлыгына беркайчан да битараф булмаган, димәк, Н. Исәнбәтнең масса җыры булып әверелгән шигырьләре – шушы зур таләпләргә җавап бирә торган иҗат.

ТФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фондлары «Идегәй»гә мөнәсәбәтле Н. Исәнбәт кулы кагылган, ул катнашкан шактый документларны саклый [8]; [9], [10], [11] һ.б.. Галимнең фольклордагы һ.б. эшчәнлегенә кагылышлы җитди хезмәтләр языла торса да [1], [12]; [13, 160–173]; [14]; [15], [16] һ.б., моңа кадәр булган тикшеренүләр генә аз, һәр документны махсус барлап, фольклорга булсын, сәнгатькә, тарихка, әдәбиятка булсын, гомумән татарларны өйрәнү фәненә – һәрбер өлкәдә Нәкый ага керткән өлешне бөртекләп җыйнап, исемен зурлап, докторлык диссертациясе якларлык, фәнни монографияләр эшләрлек потенциал бар. Бигрәк тә аның киң җәмәгатьчелеккә әлегә М. М. Хәбетдинова эшчәнлеге аша гына таныш архивы, андагы әлегәчә фәнни әйләнешкә кертелми ята торган документлар, аеруча фольклористика өлкәсенә карый торган кайберләре – фәнни даирә өчен дә, халык өчен дә бик көтелгән, гаять кызыклы материаллар [17], [18].

«Идегәй» дастанының җыйнама вариантын барлыкка китерүгә мөнәсәбәтле һ.б. вакыйгалар уңаеннан Н. Исәнбәт – Институтыбыз галимнәре белән аралашкан шәхес. Татарларны өйрәнүдә фундаменталь фәнни юнәлештә эшли торган Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият

һәм сәнгать институтында Нәкый Исәнбәт хакында төрле буын фольклорчы галимнәрендә фәнни җәһәттән фәкать якты, уңай фикерләр формалашкан. Халык иҗаты бүлегендә эшләп киткән өлкәнрәк буын фольклорчылары Нәкый аганы ихластан «бик зур галим иде ул», «искиткеч зур шәхес», «талант иясе, андый кеше татарда сирәк», «бик зур уңышларга ирешкән чын галим», «телне нечкә тоемлый алучы фольклорчы иде» дип искә алалар иде.

### Төп нәтиҗәләр

Нәтиҗә ясап әйткәндә, халыкның бетмәс-төкәнмәс хәзинәләренең кыйммәтен тирән аңлаган Нәкый аганы нәкъ менә татар фольклоры югары күтәргән, әдип үзе дә халкына һич кенә дә бурычлы калмаган. Нәкый Исәнбәт шәхесенең бөеклеге, затлылыгы да, иң беренче чиратта, аның фәннең халыкка иң якын торган өлкәсе – фольклористика белән бәйле эшчәнлегеннән килә. Нәкый аганың фольклор әсәрләре турындагы һәм гомумән татар мәдәниятенең асылын аңлап-аңлатып язган язмаларын укырга, аларны белергә, файдаланырга кирәк. Үз эшчәнлегендә гомере буе халык иҗатына таянып, аны олылаган бу шәхеснең исеме татар дөньясында бүген һәм киләчәктә еш һәм горур яңгырарга тиеш.

**Әдәбият**


1. *Ханзафаров Н.* Нәкый Исәнбәт драматургиясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 192 б.
2. Нәкый Исәнбәт: фәнни-популяр җыентык / Төз. М.М. Хәбетдинова. Казан: Җыен, 2021. 736 б.
3. *Исәнбәт Н.* Татар халык эпосы «Идегәй» дастанының 500 еллыгы // Совет әдәбияты. 1940. № 11. Б. 39–92, № 12. Б. 34–98.
4. *Урманчеев Ф.* Исәнбәт һәм татар халык иҗаты // Әдип һәм галим. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. 37–73 б.
5. *Khabutdinova M.M.* Naki Isanbet and Tatar folklore. *Tatarica*. 2024. 2 (23). 148–161 б.
6. *Хәбетдинова М.М., Хәбибуллин Ф.А.* Нәкый Исәнбәт чичәнлек сәнгате турында. Tatarica. 2021. №2 (17). 119–140 б.
7. *Исәнбәт Н.* Уракчы кыз (шигырь) // Кызыл Шәрык яшьләре. Казан, 1922. 3 б.
8. Материалы об «Идегее». Машинопись на татарском языке / ЦПН им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 52, оп. 1., ед.хр. 198. Инв. 498.
9. Пояснения к народному эпосу «Идегей». На 27 листах. 26 сентября 1941 г. / ЦПН им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 52, оп. 1., ед.хр. 210.
10. Об эпосе «Идегей». Восстание идегеистов и социально-исторические причины, способствовавшие возникновению этого эпоса. Машинопись на 38 листах. // ЦПН им. Г. Ибрагимова АН РТ. Фонд 52, оп. 1., ед.хр. 192.
11. Материалы об «Идегее. 1940 год / ЦПН ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 52. Оп. 1. Ед. хр. 201.
12. *Надиров И. Н.* Народный эпос «Идегей» // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв. ) Казань: Фэн, 1999. С. 103–106.
13. Фатих Урманчеев. Татарский народный эпос. Казань. 2023. 384 б.
14. *Хабутдинова М.М.* Вклад Наки Исанбета в изучение Золотой Орды // Золотоордынское обозрение. 2023. Т. 11, №1. С. 181–201. DOI: 10.22378/2313-6197. 2023-11-1.181-201 EDN: NZKGGK.
15. *Zamaletdinov R. R, Khabutdinova M. M.,* The creative history of Naki Isanbet's comedy "Red-haired chichyan and Black-haired beauty" // Zolotoordynskoe Obozrenie. 2023. Vol.11, Is.4. P. 934–956. DOI: 10.22378/2313 6197.2023-11-4.934-956.
16. *Khabutdinova M. M.* The History of the Creation and Promotion of the First Consolidated Text of the Bashkir Folk Epic "Idukai and Muradim" // Zolotoordynskoe obozrenie=Golden Horde Review. 2024, vol. 12, no. 4, pp. 943–969. https://doi.org/10.22378/2313-6197.2024-12-4.943-969.
17. *Исәнбәт Н.* Казан артына беренче сәяхәтем: «Оры аккан» // Tatarica. 2023. № 2 (21). 76–100 б.
18. *Исәнбәт Н.* «Коңгыр бога» көе: тарихи тамырлары һәм поэтикасы төрки халыклар мәдәнияте контекстында // Tatarica. 2023. № 1 (20). 32–43 б.


---

# НАСЛЕДИЕ ТАТАРСКОГО ФОЛЬКЛОРИСТА Н. ИСАНБЕТА


**Лилия Хатиповна Мухаметзянова,**
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан,
Россия, 420111, г. Казань, ул. Карла Маркса, д. 12,
lilmuhat@mail.ru.



Татарский фольклор – это духовное сокровище, которое создавалось народом на протяжении веков и передавалось из поколения в поколение. Фольклористика – богатая,

сложная, глубокая и влиятельная область татарской науки, составляющая духовные корни современности и имеющая исключительное значение. Не так много талантливых татарских ученых, которые посвящали свою жизнь изучению уникального наследия татарского народа и раскрытию захватывающих научных тайн этой области. Одним из редких личностей, внесших значительный вклад в популяризацию наследия татар и в сохранение национальных фольклорных памятников, которыми можно гордиться перед другими народами, является татарский писатель, фольклорист и ученый Наки Исанбет (Наки Сиразиевич Исанбет). В настоящей статье автор рассказывает о творчестве данного выдающегося деятеля, который отыскал фольклорные произведения из глубины веков, в наше время обработал их по требованиям науки и, определив ценность, передал будущим поколениям. С позиции национальных и культурных ценностей в статье дана научная оценка деятельности Н. Исанбета в области татарского фольклора и фольклористики, подчеркнута значимость предоставленных им материалов, способствующих изучению различных жанров татарского народного творчества, определен уровень перспективности проведения исследований в этом направлении.

**Ключевые слова:** татарское народное творчество, фольклористика, личность Наки Исанбета

**Для цитирования**: Мухаметзянова Л.Х. Наследие татарского фольклориста Н. Исанбета // Tatarica. 2025. № 1 (24). С. 49–58. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-49-58